КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 июнь г.Казань № 565

Татарстан республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын алу турында

«Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын (алга таба - Баштатюлтранс) тоту һәм үстерүнең төп идарәсе” дәүләт казна учреждениесенең «Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында 16:50:150312:492 кадастр номерлы 13 130 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 884 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегеннән, аның территориясендә урнашкан 16:50:150312:14 кадастр номерлы 2 038,9 кв.метр мәйдалы, 16:50:150312:18 кадастр номерлы 19,3 кв.метр мәйданлы, 16:50:150312:13 кадастр номерлы 53,8 кв.метр мәйданлы капиталь төзелеш объектларынан һәм «мобиль Телесистемалар» гавами акционер җәмгыяте милкендәге (алга таба - тартып алына торган мөлкәтнең милекчесе) Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет

районы, Зәкиев ур., 14 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларынан (алга таба - тартып алына торган мөлкәт) торган җир кишәрлеген Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен тартып алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган мөлкәт милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган мөлкәт өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен мөлкәтне алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган мөлкәт милекчесенә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган мөлкәт өчен акча түләүне;

алына торган мөлкәткә Татарстан Республикасы милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган мөлкәт милекчесе тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Баштатюлтрanска Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Зәкиев урамы адресы буенча урнашкан 13 130 кв.метр мәйданлы 16:50:150312:492 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында» 2021 ел, 06 сентябрь, 812 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты нигезендә тартып алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләре үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин